ГЛАВА
Бимского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Бима авыл жирлеге
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2021 Бима № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Бима авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең Пеләмеш торак пунктында гражданнар жыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федерал законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Бима авыл жирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Бима авыл жирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Бима авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең Пеләмеш торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының 1 этабын 2021 елның 04 декабрендә 09 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Бима авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең Пеләмеш торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының 2 этабын 2021 елның 04 декабрендә 10 сәг 00 мин билгеләргә.

3. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга:

-1 этап: Пеләмеш авылының Ленин урамында яшәүчеләр.

-2 этап: Пеләмеш авылының Заречная, Школьная, Яшьләр урамында яшәүчеләр.

4. Гражданнар жыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Бима авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең Пеләмеш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә житкән ялгыз олкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы

хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1.Пеләмеш торак пунктында Яшьләр һәм Заречная урамнары буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм җәю);

2. Пеләмеш торак пунктында урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтү, ремонтлау, лампаларны һәм фонарьларны алыштыру. Килешү буенча түләү;

3. Пеләмеш торак пунктында халыкны су белән тәэмин итү (ремонтлау, хезмәт күрсәтү, тирән насослар, колонкалар һәм башка материаллар сатып алу);

4.Пеләмеш торак пунктындагы урамнарны кардан чистарту (дизель ягулык һәм майлар сатып алу) .

5. Янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм ремонтлау. Янгын сүндерү машинасы шоферына килешү буенча түләү

6. Пеләмеш торак пунктында бензин триммеры (моточапкыч) һәм төзекләндерү өчен җиһазлар сатып алу. Килешү буенча түләү.

7.МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү. Тракторчыга килешү буенча хезмәт хакы түләү.

8.Гаражны агымдагы ремонтлау өчен материалларны сатып алу, ремонт башкару.

9.Пеләмеш торак пунктында үлән һәм чүп үләннәрен чабу. (дизель ягулык һәм майлар сатып алу).

10.Мәйдан бизәү өчен материаллар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы Пеләмеш ав., Ленин урамы, 49А йорты, мәдәният йорты янында уздырырга.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Э.И.Михайлов